**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 июль № 504

г. Казань

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын һәм аның янындагы территорияне планлаштыру проектын раслау хакында

Татарстан Республикасының Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона территориясен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 9.1 өлеш нигезендә шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын һәм аның янындагы территорияне планлаштыру проектын расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\504.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 9 июль, 504 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын һәм аның янындагы территорияне планлаштыру проекты**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын һәм аның янындагы территорияне планлаштыру проекты (алга таба – планлаштыру проекты) түбәндәгеләрне үз эченә ала:

планлаштыру проекты турында, шул исәптән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона территориясендә һәм аның янындагы территорияләрдә капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар тасвирнамәләре, махсус икътисадый зона территориясен үстерү өчен кирәкле социаль хезмәтләр, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженер-техник тәэмин итү системаларын үстерү тасвирнамәләре турында нигезләмәне;

борылыш нокталары координаталары белән кызыл сызыклар планын;

«Алабуга» СҖТ МИЗ объектларының яндагы территориядә урнашу схемасын;

инженер челтәрләре, шул исәптән су белән тәэмин итү челтәрләре, газ белән тәэмин итү челтәрләре, җылылык белән тәэмин итү челтәрләре, яңгыр сулары канализациясе челтәрләре, хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре, энергия белән тәэмин итү челтәрләре, аз токлы челтәрләр схемаларын.

________________________________________

F:\KARAR\2015\504.docx